КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 21 сентябрь г.Казань № 821

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Ел җитәкчесе» республика иҗтимагый конкурсы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2002 ел, 29 март, 161 нче карары белән расланган «Ел җитәкчесе» республика иҗтимагый конкурсы турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Ел җитәкчесе» республика иҗтимагый конкурсы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2002 ел, 29 март, 161 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 25 июль, 579 нчы; 2014 ел, 21 июль, 520 нче; 2015 ел, 1 июнь, 393 нче; 2018 ел, 14 июнь, 480 нче; 2018 ел, 29 сентябрь, 887 нче; 2020 ел, 30 октябрь, 973 нче; 2023 ел, 30 март, 378 нче; 2023 ел, 8 июль, 801 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Ел җитәкчесе» республика иҗтимагый конкурсы турындагы нигезләмәгә, 5 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«5. Конкурс уздыру регламенты

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, республика башкарма хакимият органнары катнашында, Оешма белән берлектә, ел саен, 30 апрельгә кадәр, республика социаль-икътисадый үсешенең аеруча актуаль юнәлешләрен чагылдыра торган номинацияләр һәм эшчәнлек күрсәткечләре исемлеген төзи һәм Конкурс комиссиясе рәисенә раслауга тәкъдим итә.

Конкурс комиссиясе рәисе ел саен, 1 июньгә кадәр, конкурска йомгаклар ясалачак номинацияләр һәм эшчәнлек күрсәткечләре исемлеген карый һәм раслый.

Оешма ел саен, 30 июньгә кадәр, республика башкарма хакимият органнары җитәкчеләренә, муниципаль районнар һәм шәһәр округлары башлыкларына, эш бирүчеләр берләшмәләре һәм һөнәр берлекләре җитәкчеләренә конкурска йомгаклар ясалачак номинацияләр һәм эшчәнлек күрсәткечләре исемлеген раслау турында һәм агымдагы елда предприятиеләр һәм оешмаларның киң даирәсендәге эшчәнлек нәтиҗәләрен анализлау нигезендә конкурста катнашучылар буенча тәкъдимнәр тапшыру кирәклеге турында хәбәр итә.

Республика башкарма хакимият органнары, муниципаль районнар һәм шәһәр округлары башлыклары, эш бирүчеләр берләшмәләре һәм Татарстан Республикасының һөнәри берлекләре ел саен, 25 октябрьгә кадәр, Оешмага һәр номинациягә конкурста катнашучылар турында өч тәкъдим, ә Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы, Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы тиешле материаллар белән һәр номинациягә конкурста катнашучы турында кимендә бер тәкъдим кертә, шул исәптән:

конкурста катнашучы турында белешмә кәгазе;

конкурста катнашучы җитәкли торган предприятие (оешма) турында белешмә кәгазе;

конкурста катнашучы җитәкли торган предприятиенең (оешманың) катнашучы тәкъдим ителгән номинациягә караган эшчәнлек күрсәткечләре;

әлеге номинация буенча конкурска катнашучыны тәкъдим итүнең кыскача нигезләмәсе (0,5 машина язу кәгазе күләмендә).

Дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы ел саен, 15 ноябрьгә кадәр, конкурста катнашучылар җитәкли торган предприятиеләрне һәм оешмаларны кертеп, предприятиеләр һәм оешмалар рейтингын (икътисадый эшчәнлек төрләре буенча) билгели һәм аны Оешма адресына җибәрә.

Оешма ел саен, 15 ноябрьгә кадәр, конкурска тапшырылган материалларның тулылыгын, аларны төгәлләштерүне һәм тулыландыруны тикшерә. Тикшерү нәтиҗәләре буенча конкурсның номинантлары исемлеге, ягъни һәр номинация буенча конкурс лауреаты исемен алуга дәгъва кылучылар исемлеге төзелә.

Оешма ел саен, 25 ноябрьгә кадәр, Дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы тарафыннан тапшырылган рейтинглы бәяләүне исәпкә алып, һәр номинация буенча конкурс номинантлары эшчәнлеге күрсәткечләрен эшкәртүне, системалаштыруны һәм анализлауны гамәлгә ашыра.

Конкурс комиссиясе ел саен, 5 декабрьгә кадәр, тәкъдим ителгән тәкъдимнәрнең эксперт бәяләмәсе бирелә торган конкурс номинантлары исемлеген карау буенча алдан утырыш үткәрә.

Оешма ел саен, 10 декабрьгә кадәр, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы белән берлектә, Конкурс комиссиясе рәисенә кертү өчен конкурс лауреатлары исеменә кандидатуралар турында тәкъдимнәр формалаштыра.

Конкурс комиссиясе ел саен, 15 декабрьгә кадәр:

конкурс номинантлары буенча тәкъдим ителгән материалларны һәм конкурс лауреаты исеменә кандидатуралар турында тәкъдимнәрне карау буенча утырыш үткәрә;

утырышта катнашучы Конкурс комиссиясе әгъзаларының күпчелек тавышы белән, ачык тавыш биреп, конкурс лауреатлары турында карар кабул итә.

Конкурс комиссиясе утырышы, әгәр анда әгъзаларының кимендә яртысы катнашса, хокуклы дип санала.

Тавышлар саны тигез булганда, Конкурс комиссиясе рәисенең тавышы хәлиткеч була.

Шул ук вакытта һәр номинациядә конкурс лауреатлары итеп, кагыйдә буларак, ике, әмма икътисадның төрле тармакларына һәм өлкәләренә караган өч предприятие һәм оешма җитәкчесе билгеләнә.

Ел саен, декабрьнең өченче декадасында, Татарстан Республикасы Рәисе һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, муниципаль берәмлекләр, эш бирүчеләр берләшмәләре, һөнәри берлекләр, фәнни оешмалар һәм берләшмәләр вәкилләре, танылган сәнәгатьчеләр һәм эшкуарлар, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре катнашында конкурс лауреатларын бүләкләү тантанасы уздырыла.

Конкурс йомгаклары массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртыла.

Конкурс йомгаклары буенча ел саен истәлекле китап басылып чыга, ул республика башкарма хакимият органнарына, муниципаль берәмлекләргә, эш бирүчеләр берләшмәләренә һәм һөнәри берлекләргә, Татарстан Республикасы Милли китапханәсенә җибәрелә, шулай ук конкурсның һәр лауреатына тапшырыла.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин